Республика Татарстан
Глава
Вахитовского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

ул.Центральная, д. 30,
пос.Победа
Азнакаевский район, 423312

Үзәк урамы, 29 нче йорт, Җиңү
бистәсе, Азнакай районы, 423312

Тел. (факс) 8(85592) 42-1-38; e-mail: Vahit.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» ноябрь 2021 ел. №5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитовы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Җиңү торак пункты Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2021 елнын 4 декабрендә 9.00 сәгать 00 минутта Җиңү бистәсе Яшьләр урамы 1 йорттан 16 йортка, Яшел урам 1 йорттан 49 йортның 4 фатирын кертеп теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Җиңү торак пунктында 2022 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Җиңү торак пунктында Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2021 елнын 4 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Җиңү бистәсе Яшел урам 49 йортның 5 фатирыннан 89 йортка, Кибет урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Җиңү торак пунктында 2022 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Җиңү торак пунктында Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2021 елнын 4 декабрендә 11 сәгать 00 минутта Җиңү бистәсе Татарстан урамы 1 йорттан 10 йортка, Үзәк тыкрык урамы 1 йорттан 3 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2022 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының өченче этабын** билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Җиңү торак пунктында Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2021 елнын 4 декабрендә 13.00 сәгать минутта Җиңү торак пункты Үзәк урамы 1А йорттан фатир 5,13 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2022 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының дүртенче этабын** билгеләргә.

5.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2021 елнын 4 декабрендә 14.00 сәгать минутта Җиңү торак пункты Үзәк урамы 6 фатир,47 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2022 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе **гражданнар җыенының бишенче этабын** билгеләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Җиңү торак пунктында урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча эшләр өчен түләү)
- Җиңү торак пунктында “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Халыкара өлкәннәр көне”, «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;
- Җиңү торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Җиңү торак пунктында МТЗ-80 тракторына фронталь төягеч (виллар, ковш) сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай районы Вахитов
авыл җирлеге башлыгы И.Б. Бохарова